КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 ноябрь г.Казань № 895

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары һәм карарларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 16 июнь, 411 нче; 2014 ел, 25 октябрь, 777 нче; 2015 ел, 25 февраль, 115 нче; 2015 ел, 29 июнь, 468 нче; 2016 ел, 15 февраль, 93 нче; 2016 ел, 26 август, 590 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 668 нче; 2016 ел, 25 октябрь, 778 нче; 2017 ел, 4 февраль, 61 нче; 2017 ел, 26 июнь, 435 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 768 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 817 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа Паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләме | Дәүләт программасын финанслауның гомуми күләме 150 167 157,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 55 533 170,7 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 92 077 546,0 мең сум һәм җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан – 2 556 441,0 мең сум, шулардан түбәндәгеләрне тормышка ашыруга:<br>«Үсемлекчелек ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасын – 56 509 152,6 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 22 922 972,8 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 33 586 179,8 мең сум;<br>«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасын – 32 506 984,6 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 19 994 762,5 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 12 512 222,1 мең сум;<br>«Итле терлекчелекне үстерү» ярдәмче программасын – 339 255,5 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 112 714,5 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 226 541,0 мең сум;<br>«Хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык күрсәтү» ярдәмче программасын – 5 873 262,9 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 2 415 975,6 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 357 287,3 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 100 000,0 мең сум;<br>«Техник һәм технологик модернизацияләү, инновацион үсеш» ярдәмче программасын – 16 043 192,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 16 043 192,7 мең сум; |

«Дәүләт программасын тормышка ашыруны тәэмин итү» ярдәмче программасын – 12 094 550,7 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 6 087 089,1 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 6 007 461,6 мең сум;

«Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын – 15 181 911,5 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 3 441 519,8 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 11 740 391,7 мең сум;

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мелиорациясен үстерү» ярдәмче программасын – 6 479 596,8 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 558 136,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 3 465 019,4 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 2 456 441,0 мең сум;

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасын – 5 139 250,4 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 5 139 250,4 мең сум.

Еллар буенча Дәүләт программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме түбәндәгеләрне тәшкил итәчәк:

| Ел | Акча күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджетыннан | федераль бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2013 | 7 821 363,1 | 11 078 525,8 | 3 437,0 |
| 2014 | 10 387 324,3 | 9 851 733,4 | 966 203,8 |
| 2015 | 14 863 994,8 | 11 989 745,3 | 205 300,0 |
| 2016 | 11 862 462,8 | 10 175 709,4 | 175 589,0 |
| 2017 | 15 894 040,0 | 8 651 672,4 | 453 911,2 |
| 2018 | 10 067 201,2 | 1 915 340,5 | 248 000,0 |
| 2019 | 10 067 201,2 | 1 870 443,9 | 251 000,0 |
| 2020 | 11 113 958,6 | * | 253 000,0 |
| Бар-лыгы | 92 077 546,0 | 55 533 170,7 | 2 556 441,0 |

| | |
|---|---|
| | Дәүләт программасы юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк. *Дәүләт программасын федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме чыгымнары Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашу шартларында Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Татарстан Республикасы ел саен төзи торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Дәүләт программасының төп чаралары һәм аның ярдәмче программаларының гомумиләштерелгән тасвирламасы

Ярдәмче программалар һәм аларга кертелгән төп чаралар, шулай ук максатчан программалар модернизация һәм инновацион эшләү моделенә күчү нигезендә агросәнәгать комплексының социаль-икътисадый үсешен тәэмин иткән агымдагы һәм перспективадагы максатларны һәм бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән бер-берсенә бәйле чаралар комплексын тәшкил итә.

«Үсемлекчелек ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасы түбәндәге төп чараларны үз эченә ала:

затлы орлыкчылыкны үстерү;

күпьеллык җимеш һәм җиләк үсентеләрен утыртуга һәм карап үстерүгә ярдәм күрсәтү;

үсемлекчелек ярдәмче тармакларында куркынычлар белән идарә итү;

туфракларның уңдырышлылыгын арттыру һәм авыл хуҗалыгы биләмәләренең файдаланылмый торган җирләрен авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертү.

Әлеге ярдәмче программаларның максатчан индикаторлары сыйфатында үсемлекчелек продукциясенең, үсемлекчелек чималыннан чыгарыла торган азык-төлек продуктларының төп төрләрен җитештерү күләмнәре файдаланыла.

«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасында түбәндәге төп чаралар аерып чыгарыла:

нәселле терлекчелеккә дәүләт ярдәме күрсәтү;

сөтле терлекчелекне үстерү;

сарыклар һәм кәҗәләр үрчетүне үстерү;

эпизоотиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү;

терлекчелек ярдәмче тармакларында куркынычлар белән идарә итү;

хайваннар авыруларын кисәтү һәм халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда сугымга терлек һәм кош-корт, сырлар, ак май җитештерү, терлек чалу һәм аны беренчел эшкәртү буенча җитештерү куәтләре күләмнәре тора.

«Итле терлекчелекне үстерү» ярдәмче программасы итлек терлекчелекнең нәсел базасын үстерү чараларын үз эченә ала.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторы булып авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында махсуслаштырылган итле токымнар белән катнаш кушылдырып алынган кушылгак терлекнең һәм махсуслаштырылган итле токымлы мөгезле эре терлекнең баш саны тора.

«Хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык күрсәтү» ярдәмче программасы кече эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү өлкәсендә чараларны алга таба үстерүне тәшкил итә һәм үз эченә түбәндәге чараларны ала:

эшләрен башлап җибәрүче фермерларга ярдәм күрсәтү;

крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү;

хуҗалык итүнең кече формаларына кредит бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтү;

гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләренә ярдәм күрсәтү.

Әлеге ярдәмче программаның индикаторлары булып үз хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын дәүләт ярдәме белән гамәлгә ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары, эшләрен башлап җибәрүче фермерлар саны, төзелгән яки төзекләндерелгән гаилә терлекчелек фермалары саны һәм махсуслаштырылган предприятиеләр балансына бирелгән электр линияләре белән, шулай ук каты өслекле керү юллары белән тәэмин ителгән, су белән тәэмин итү яхшыртылган һәм каты көнкүреш коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару оештырылган гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциячел булмаган берләшмәләре өлешен арттыру тора.

«Техник һәм технологик модернизацияләү, инновацион үсеш» ярдәмче программасы үз эченә түбәндәге чараларны ала:

авыл хуҗалыгы техникасы паркын яңарту;

агросәнәгать комплексында перспективалы инновацион проектларны тормышка ашыру;

биотехнологияләрне үстерү.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып түбәндәгеләр тора:

теләсә кайсы милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр тарафыннан яңа техника сатып алу күләмнәре;

чәчүлек мәйданының 100 гектарына авыл хуҗалыгы оешмаларының энергия белән тәэмин ителеше (тракторлар, комбайннар һәм үзйөрешле машиналар двигательләренең кушылган номиналь егәрлеге);

гамәлгә ашырылган инновацион проектлар саны;

үсемлекчелектә үсемлекләрне һәм микробиологик ашламаларны саклауның биологик чаралары кулланылышы үсеше;

биотехнология ысуллары белән эшкәртелгән авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларының чагыштырма авырлыгы.

«Дәүләт программасын тормышка ашыруны тәэмин итү» ярдәмче программасы үз эченә түбәндәге төп чараларны ала:

Дәүләт программасын тормышка ашыруны идарәчелек ягыннан тәэмин итүне камилләштерү;

Дәүләт программасын тормышка ашыруны кадрлар белән тәэмин итүне үстерү;

Дәүләт программасын тормышка ашыруны фәнни яктан тәэмин итүне үстерү;

агросәнәгать комплексында кредит бирүгә ярдәм күрсәтү.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының соңгы өч ел эчендә квалификациясен күтәргән дәүләт граждан хезмәткәрләре өлеше;

Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары комплектланган булу;

азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм агросәнәгать комплексы белән идарә итү өлкәләрендә дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан файдалана торган агросәнәгать комплексының муниципаль идарә органнары өлеше;

предприятиеләр белән фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре башкаруга (фәнни-техник хезмәтләр күрсәтүгә) шартнамәләр буенча фәнни оешмаларга кергән акча күләме.

«Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасында түбәндәге төп чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

авыл җирендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту;

авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү;

авыл җирлекләрен комплекслы компактлы төзүгә ярдәм күрсәтү.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып авыл җирендә яшәүче гражданнар, шул исәптән яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торакны гамәлгә кертү (сатып алу), авылның социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын гамәлгә кертү, комплекслы компактлы төзелеш проектлары тормышка ашырылган авыл җирлекләре саны тора.

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мелиорациясен үстерү» ярдәмче программасында түбәндәге төп чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү һәм төзекләндерү;

фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре;

культуртехника, агро-урман-мелиорация һәм фитомелиорация чаралары;

язгы ташуга каршы чаралар.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып түбәндәгеләр тора:

культуртехника эшләре, чүлгә әйләнгән җирләргә агро-урман-мелиорация һәм фитомелиорация үткәрү хисабына авыл хуҗалыгы биләмәләренең авыл хуҗалыгы әйләнешеннән чыгуын булдырмау;

Дәүләт программасын тормышка ашыру еллары эчендә авыл хуҗалыгы продукциясе артымы;

яңа эш урыннары булдыру.

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» ярдәмче программасында түбәндәге төп чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

сыер абзарларын капиталь ремонтлау;

торак пунктларда модульле-блоклы ветеринария пунктлары төзү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең ведомство буйсынуындагы учреждениеләре биналарын капиталь ремонтлау;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре биналарын капиталь ремонтлау;

Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру индикаторлары булып ремонт ясалган сыер абзарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең ведомство буйсынуындагы учреждениеләре биналары, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре биналары һәм торак пунктларда төзелгән модульле-блоклы ветеринария пунктлары саны тора.».;

Программаның VI бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт программасын финанслауның гомуми күләме 150 167 157,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 55 533 170,7 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 92 077 546,0 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан – 2 556 441,0 мең сум.»;

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү» дигән 2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 таблица

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

(мең сум)

| Ярдәмче программа исеме | Финанслау чыганагы | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Дәүләт программасы буенча барлыгы | барлыгы | 18 903 325,9 | 21 205 261,5 | 27 059 040,1 | 22 213 761,2 | 24 999 623,6 | 12 230 541,7 | 12 188 645,1 | 11 366 958,6 |
| | федераль бюджет* | 11 078 525,8 | 9 851 733,4 | 11 989 745,3 | 10 175 709,4 | 8 651 672,4 | 1 915 340,5 | 1 870 443,9 | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 7 821 363,1 | 10 387 324,3 | 14 863 994,8 | 11 862 462,8 | 15 894 040,0 | 10 067 201,2 | 10 067 201,2 | 11 113 958,6 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар** | 3 437,0 | 966 203,8 | 205 300,0 | 175 589,0 | 453 911,2 | 248 000,0 | 251 000,0 | 253 000,0 |
| Үсемлекчелек ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү | барлыгы | 9 646 326,2 | 8 235 638,6 | 11 757 808,4 | 8 851 588,1 | 6 336 418,8 | 3 740 357,0 | 3 707 018,5 | 4 233 997,0 |
| | федераль бюджет* | 5 664 617,9 | 4 082 490,4 | 6 073 788,7 | 3 813 755,2 | 656 945,1 | 1 332 357,0 | 1 299 018,5 | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 3 981 708,3 | 4 153 148,2 | 5 684 019,7 | 5 037 832,9 | 5 679 473,7 | 2 408 000,0 | 2 408 000,0 | 4 233 997,0 |
| Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү | барлыгы | 6 392 010,4 | 5 968 027,7 | 8 301 706,0 | 6 224 764,8 | 1 210 721,8 | 1 623 968,7 | 1 612 410,6 | 1 173 374,6 |
| | федераль бюджет* | 4 572 089,3 | 4 360 598,7 | 4 334 123,1 | 5 085 023,5 | 488 519,0 | 582 983,5 | 571 425,4 | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 1 819 921,1 | 1 607 429,0 | 3 967 582,9 | 1 139 741,3 | 722 202,8 | 1 040 985,2 | 1 040 985,2 | 1 173 374,6 |
| Итле терлекчелекне үстерү | барлыгы | 3 024,0 | 24 522,2 | 185 277,1 | 23 891,2 | - | 5 200,0 | 5 200,0 | 92 141,0 |
| | федераль бюджет* | 3 024,0 | 22 522,2 | 67 277,1 | 19 891,2 | - | * | * | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | - | 2 000,0 | 11 8000,0 | 4 000,0 | - | 5 200,0 | 5 200,0 | 92 141,0 |
| Хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык күрсәтү | барлыгы | 824 261,4 | 657 002,8 | 702 020,3 | 1 128 253,4 | 1 465 000,0 | 325 000,0 | 325 000,0 | 446 725,0 |
| | федераль бюджет* | 429 058,2 | 468 502,8 | 593 242,3 | 435 172,3 | 490 000,0 | * | * | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 395 203,2 | 188 500,0 | 108 778,0 | 693 081,1 | 875 000,0 | 325 000,0 | 325 000,0 | 446 725,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бюджеттан тыш чыганаклар** | - | - | - | - | 100 000,0 | - | - | - |
| Техник һәм технологик модернизацияләү, инновацион үсеш | барлыгы | 351 947,0 | 1 709 193,8 | 1 894 192,0 | 1 896 573,9 | 4 167 655,0 | 1 967 655,0 | 1 967 655,0 | 2 088 321,0 |
| | федераль бюджет* | - | - | - | - | - | - | | |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 351 947,0 | 1 709 193,8 | 1 894 192,0 | 1 896 573,9 | 4 167 655,0 | 1 967 655,0 | 1 967 655,0 | 2 088 321,0 |
| Дәүләт программасын тормышка ашыруны тәэмин итү | барлыгы | 304 271,0 | 251 483,4 | 833 714,3 | 982 883,9 | 7 475 698,1 | 916 500,0 | 916 500,0 | 413 500,0 |
| | федераль бюджет* | - | - | - | | 6 087 089,1 | * | * | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 304 271,0 | 251 483,4 | 833 714,3 | 982 883,9 | 1 388 609,0 | 916 500,0 | 916 500,0 | 413 500,0 |
| Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү | барлыгы | 970 500,4 | 2 749 122,3 | 1 431 858,5 | 1 280 935,5 | 1 685 994,8 | 2 354 500,0 | 2 354 500,0 | 2 354 500,0 |
| | федераль бюджет* | 373 679,4 | 740 687,3 | 753 102,6 | 713 154,2 | 860 896,3 | * | * | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 596 821,0 | 2 008 435,0 | 678 755,9 | 567 781,3 | 825 098,5 | 2 354 500,0 | 2 354 500,0 | 2 354 500,0 |
| Авыл хуҗа-лыгы билгеләнешендәге җирләр мелиорациясен үстерү | барлыгы | 410 985,5 | 1 610 270,7 | 862 441,5 | 803 965,0 | 868 534,1 | 678 000,0 | 681 000,0 | 564 400,0 |
| | федераль бюджет* | 36 057,0 | 176 932,0 | 168 211,5 | 108 713,0 | 68 222,9 | * | * | * |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 371 491,5 | 467 134,9 | 488 930,0 | 519 663,0 | 446 400,0 | 430 000,0 | 430 000,0 | 311 400,0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар** | 3 437,0 | 966 203,8 | 205 300,0 | 175 589,0 | 353 911,2 | 248 000,0 | 251 000,0 | 253 000,0 |
| Дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү | барлыгы | - | - | 1 090 022,0 | 1 020 905,4 | 1 789 601,0 | 619 361,0 | 619 361,0 | - |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 1 090 022,0 | 1 020 905,4 | 1 789 601,0 | 619 361,0 | 619 361,0 | - |

* Федераль бюджет акчасы күләмнәре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән ел саен төзи торган килешүләр нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу шартларында җәлеп итәргә планлаштырыла һәм Татарстан Республикасы бюджетына биреләчәк.
** Билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча.»;

«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа Паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="13">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td colspan="3">Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 32 506 984,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 19 994 762,5 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 12 512 222,1 мең сум.<br>Еллар буенча Ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>2013</td><td>1 819 921,1</td><td>4 572 089,3</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 607 429,0</td><td>4 360 598,7</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>3 967 582,9</td><td>4 334 123,1</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 139 741,3</td><td>5 085 023,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>722 202,8</td><td>488 519,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 040 985,2</td><td>582 983,5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 040 985,2</td><td>571 425,4</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 173 374,6</td><td>*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>12 512 222,1</td><td>19 994 762,5</td></tr>
<tr><td colspan="3">Ярдәмче программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммасы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.<br>*Ярдәмче программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашу шартларында Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары ел саен төзи торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;</td></tr>
</table>

Ярдәмче программаның III бүлегендә:

7 нче һәм 8 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Хайваннар авыруларын кисәтү һәм халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау» чарасы

Чараны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы территориясен һәм халыкны биологик характердагы тискәре йогынтылардын һәм куркынычлардан саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелә.

Хайваннарның авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау, шул исәптән түләмәле үләт базларын һәм биотермик корылмаларны карап тоту, шулай ук хуҗалары булмаган хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу буенча чаралар үткәрү күздә тотыла.

8. Татарстан Республикасының икътисадый әһәмиятле ярдәмче программаларын эшләү

Дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасының түбәндәге икътисадый әһәмиятле ярдәмче программаларын эшләү планлаштырыла:

«Сөтле терлекчелекне үстерү»;

«Селекция-генетикалы һәм селекция-гибридлы дуңгызчылык үзәкләрен үстерү»;

«Дуңгызчылык продукциясен тирәнтен эшкәртүне үстерү»;

«Терлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм сатуны үстерү».

«Сөтле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмиятле ярдәмче программасы сөт җитештерү рентабельлеген һәм сөтле терлекчелекнең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, мөгезле эре терлекнең, шул исәптән сыерларның баш санын саклап калуга һәм стабильләштерүгә, терлекчелектә арттырып үрчетү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелә.

«Селекция-генетикалы һәм селекция-гибридлы дуңгызчылык үзәкләрен үстерү» икътисадый әһәмиятле ярдәмче программасы кисешелгән яшь терлекне йомык линияле чиста токымлы үрчетү һәм алу ысулы белән дуңгызларның «ана» һәм «ата» махсуслаштырылган берләштерелгән линияләрен чыгаруга һәм нәселле терлекне камилләштерүгә юнәлдерелә.

«Дуңгызчылык продукциясен тирәнтен эшкәртүне үстерү» икътисадый әһәмиятле ярдәмче программасы дуңгызларны чалу, итен беренчел һәм тирәнтен эшкәртү буенча яңа егәрлекләрне гамәлгә кертү, энергия нәтиҗәлелекле заманча җайланмасын кулланып, инновацион ресурсларны саклый торган технологияләр нигезендә яңа технологик процессларны кулланышка кертү хисабына югары сыйфатлы тасвирламалар белән дуңгызчылык продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыруга юнәлдерелә.

«Терлекчелек продукциясен эшкәртүне һәм сатуны үстерү» икътисадый әһәмиятле ярдәмче программасы азык-төлек чылбырларын, төбәк азык-төлек (ит һәм сөт) кластерларын формалаштыру өчен шартлар тудыруга юнәлдерелә.

Татарстан Республикасының әлеге икътисадый әһәмиятле ярдәмче программаларын финанслау федераль норматив актлар белән билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмнәрдә икътисадый әһәмиятле ярдәмче программаны сайлап алу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчасы исәбеннән карала.»;

Ярдәмче программаның IV бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаны тормышка ашыруга финанслауның гомуми күләме 32 506 984,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 19 994 762,5 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 12 512 222,1 мең сум.»;

«2013 – 2020 елларга «Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары» дигән 5 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 таблица

2013 – 2020 елларга «Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты – импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерүне комплекслы үстерү һәм нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012 (база) ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Сөтле һәм итле терлекчелек, кошчылык продукциясен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру | Сөтле терлекчелекне үстерү | Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда сөт җитештерү, мең тонна | 1 888 | 1 960 | 1 963 | 1 984 | 2 015 | 1 794,1 | 1 804,4 | 1 815,5 | 1 826 |
| | | | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сөт җитештерү, мең тонна | - | - | - | - | - | 1220 | 1240 | 1260 | 1280 |
| | Нәселле терлекчелек | | Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда сугымга терлек һәм кошкорт җитештерү (тере авырлыкта), мең тонна | 456 | 440 | 455 | 470 | 496 | 490 | 495 | 500 | 505 |
| | | | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, махсуслаштырылган итле токымнан булган сыер башының товар саны, мең баш | - | - | - | - | - | 1,53 | 1,56 | 1,6 | 1,63 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Иминиятләштерелгән авыл хуҗалыгы хайваннарының баш саны, мең шартлы баш | - | - | - | - | - | 45 | 47,3 | 49,7 | 52,2 |
| | Терлекчелек ярдәмче тармагына, аның продукциясен эшкәртүгә, терлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистик тәэмин ителешен үстерүгә кредит бирү буенча дәүләт ярдәме | | Терлекне чалу һәм беренчел эшкәртү буенча җитештерү куәтләре артымы, мең тонна | 14,2 | 14,4 | 2,1 | 2,7 | 3,6 | - | - | - | - |
| | | | Йомырка җитештерү, млн.данә | 1 120,2 | 1 100 | 1 150 | 1 180 | 1 200 | 1 170,7 | 1 200 | 1 220 | 1 240 |
| | | | Сырлар һәм сыр продуктлары җитештерү, мең тонна | 31,5 | 33,1 | 33,1 | 33,5 | 33,6 | 18,0 | 20,0 | 21,0 | 22,0 |
| | | | Ак май җитештерү, мең тонна | 21,7 | 22,5 | 22,5 | 22,6 | 22,9 | 16,0 | 16,2 | 16,5 | 17,0 |
| Халыкның традицион яшәү рәвеше һәм мәшгульлеге саклануын тәэмин итүче терлекчелекнең социаль әһәмияттәге тармакларын үстерү | Сарыклар һәм кәҗәләр үрчетүне үстерү | Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сарыкларның һәм кәҗәләрнең ана баш саны, мең баш | 23,0 | 25,1 | 25,5 | 26,0 | 26,4 | 32,0 | 32,1 | 32,2 | 32,3 |
| Хайваннарның һәм кошларның йогышлы авырулары барлыкка килүне | Эпизоотиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү | | Авыруларга тиз бирешүчән хайваннарның баш санын дуңгызларның африка чумасына тикшерү, дуңгызларның баш саныннан үткәрелгән тикшерүләр саны проценты | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| һәм таралуны кисәтү | | органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасы территориясендә дуңгызларның африка чумасын китереп чыгаручы ачыкланылышы, тикшерүләрнең гомуми санынна уңай пробалар проценты | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Терлекчелек ярдәмче тармакларында куркынычлар белән идарә итү | | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сөтнең товарлылыгы, процент | - | - | - | 90 | 90,5 | 90 | 90 | 90 | 90 |
| | | | Сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең гомуми ана баш санында сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең идентификацияләнгән ана баш саны чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | - | | 50 | 80 | 90 | 100 |
| | | | Сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) эксплуатациягә кертелгән терлек урыннары саны, мең терлек урыны | - | - | - | 1,0 | 1,2 | 1,6 | 1,2 | 1,2 | 1,2 |
| | | | Узган ел дәрәҗәсенә карата авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле шартлы ана баш саны саклануы, процент | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100,2 | 100 | 100,2 |
| | | | 100 ана башка сөтле һәм итле токымнан булган мөгезле эре нәселле яшь терлекне реализацияләү, баш | - | - | - | - | - | 10 | 10 | 10 | 10 |
| | | | Гамәлгә кертелгән селекция-генетика үзәкләре саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 1 | - | - |
| | | | Сөтле сыерларның гомуми баш санында сөтчелек юнәлешендәге нәселле сыерларның чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | 23,5 | 23,6 | 23,7 | 23,8 | 23,9 | 24 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Хайваннар авыруларын кисәтү һәм халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау | | Түләмәле үләт базларын һәм билтермик калдыкларын карап тоту, корылмаларның нормативларга туры килү дәрәҗәсенә процент | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 |
| | | | Хуҗалары булмаган хайваннарны тоту, карап тоту һәм санын җайга салу, хуҗалары булмаган хайваннар санын җайга салу буенча башкарылган барлык план буенча чаралар проценты | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100»; |

«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү» дигән 6 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 таблица

«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

(мең сум)

| Бурыч исеме | Чара исеме | Финанслау чыганагы | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Сөтле һәм итле терлекчелек, кошчылык продукциясен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру, хайваннарның һәм кошларның йогышлы | Ярдәмче программа буенча барлыгы | барлыгы | 6 392 010,4 | 5 968 027,7 | 8 301 706,0 | 6 224 764,8 | 1 210 721,8 | 1 623 968,7 | 1 612 410,6 | 1 173 374,6 |
| | | федераль бюджет* | 4 572 089,3 | 4 360 598,7 | 4 334 123,1 | 5 085 023,5 | 488 519,0 | 582 983,5 | 571 425,4 | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 1 819 921,1 | 1 607 429,0 | 3 967 582,9 | 1 139 741,3 | 722 202,8 | 1 040 985,2 | 1 040 985,2 | 1 173 374,6 |
| | «Сөтле терлекчелекне үстерү» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | 851 694,1 | 476 574,4 | 453 763,7 | 614 696,6 | 332 419,0 | 582 983,5 | 571 425,4 | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 572 960,5 | 367 483,1 | 257 413,2 | 276 865,2 | 280 000,0 | 280 000,0 | 280 000,0 | 396 329,0 |
| | сөтчелек юнәлешендәге мөгезле | федераль | 851 694,1 | 476 574,4 | 453 763,7 | 614 696,6 | 332 419,0 | 582 983,5 | 571 425,4 | * |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| авырулары барлыкка килүне һәм таралуны кисәтү һәм халыкның традицион яшәү рәвеше һәм мәшгульлеге саклануын тәэмин итүче терлекчелекнең социаль әһәмияттәге тармакларын үстерү | эре терлекнең продуктивлыгын арттыруга субсидияләр | бюджет* | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 572 960,5 | 367 483,1 | 257 413,2 | 276 865,2 | 280 000,0 | 280 000,0 | 280 000,0 | 396 329,0 |
| | «Нәселле терлекчелеккә дәүләт ярдәме» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | 162 638,2 | 77 703,8 | 113 195,4 | 120 042,0 | 150 000,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 317 810,6 | 304 810,6 | 575 493,6 | 315 215,9 | 305 000,6 | 311 000,6 | 311 000,6 | 350 000,0 |
| | нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтүгә субсидияләр | федераль бюджет* | 162 638,2 | 77 703,8 | 113 195,4 | 15 845,9 | 150 000,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 310 000,0 | 296 500,0 | 566 293,6 | 171 161,7 | 300 890,0 | 183 890,0 | 183 890,0 | 350 000,0 |
| | сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә ярдәм күрсәтүгә субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | - | 104 196,1 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | 140 147,0 | - | 123 000,0 | 123 000,0 | - |
| | нәселле атлар үрчетүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 7 810,6 | 8 310,6 | 9 200,0 | 3 907,2 | 4 110,6 | 4 110,6 | 4 110,6 | - |
| | «Терлекчелек ярдәмче тармакларында куркынычлар белән идарә итү» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | 28 600,5 | 32 032,4 | 43 902,1 | 14 573,8 | 5 000,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 19 067,0 | 21 400,0 | 2 311,0 | 1 041,0 | 263,2 | 5 000,0 | 5 000,0 | 13 000,0 |
| | терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы иминиятләштерүе шартнамәсе буенча күчерелгән иминият премиясен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга | федераль бюджет* | 28 600,5 | 32 032,4 | 43 902,1 | 14 573,8 | 5 000,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 19 067,0 | 21 400,0 | 2 311,0 | 1 041,0 | 263,2 | 5 000,0 | 5 000,0 | 13 000,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | субсидияләр | | | | | | | | | |
| | «Терлекчелек ярдәмче тармагына, аның продукциясен эшкәртүгә, терлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистик тәэмин ителешен үстерүгә кредит бирү буенча дәүләт ярдәме» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | 2 956 466,9 | 3 774 288,1 | 3 719 679,3 | 3 207 728,6 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 340 000,0 | 290 792,5 | 313 392,1 | 361 023,7 | - | 216 800,0 | 216 800,0 | 237 800,0 |
| | терлекчелекне, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерүгә кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | 791 196,0 | 361 873,5 | 550 425,8 | 56 723,2 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 70 000,0 | 45 437,7 | 50 000,0 | 27 051,9 | - | 20 000,0 | 20 000,0 | 71 060,0 |
| | күпләп сату-бүлү үзәкләрен үстерү өлкәсендә үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | 5 780,6 | 1 500,0 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 2 000,0 | 500,0 | - | 5 000,0 | 5 000,0 | - |
| | терлекчелекне үстерүгә, терлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистик тәэмин ителешен эшкәртүгә һәм үстерүгә инвестиция кредитлары (заемнар) буенча процент ставкасының бер өлешен субсидияләү | федераль бюджет* | 2 165 270,9 | 3 412 414,6 | 2 534 561,6 | 1 962 121,7 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 270 000,0 | 245 354,8 | 226 392,1 | 221 042,7 | - | 73 800,0 | 73 800,0 | 166 740,0 |
| | сөтле терлекчелекне үстерүгә кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | 12 431,7 | 202 019,4 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | 1 000,0 | 19 100,0 | - | 13 000,0 | 13 000,0 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сөтле терлекчелек өчен объектлар төзү һәм төзекләндерүгә инвестиция кредитлары (заемнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | 616 479,6 | 985 364,3 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 34 000,0 | 93 329,1 | - | 105 000,0 | 105 000,0 | - |
| | «Эпизоотиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 106 972,8 | 78 398,0 | 88 567,0 | 52 519,8 | 55 000,0 | 45 000,0 | 45 000,0 | 41 000,0 |
| | ветеринария-санитария савыктыруы буенча чаралар | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 96 972,8 | 56 398,0 | 88 567,0 | 42 519,8 | 45 000,0 | 35 000,0 | 35 000,0 | 41 000,0 |
| | Татарстан Республикасы территориясендә дуңгызларның африка чумасы керүен һәм таралуын булдырмау буенча чаралар | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 10 000,0 | 22 000,0 | - | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | - |
| | «Терлекчелеккә дәүләт ярдәме күрсәтү» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | 572 689,6 | - | - | 34 994,7 | 1 100,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 463 110,2 | 544 544,8 | 2 730 217,0 | 75 550,0 | 81 939,0 | 81 939,0 | 81 939,0 | 64 000,0 |
| | азыклар кыйммәтләнүгә бәйле субсидияләр | федераль бюджет* | 416 537,6 | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 120 930,3 | - | - | - | - | - | - | - |
| | терлекчелек өлкәсендә икътисадый әһәмияттәге төбәк программаларына ярдәм күрсәтүгә субсидияләр | федераль бюджет* | 156 152,0 | - | - | 33 911,0 | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы | 231 980,0 | | | 12 000,0 | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | бюджеты | | | | | | | | |
| | сарыклар һәм кәҗәләрнең ана башларын үрчетүне үстерү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | | | | 1 083,7 | 1 100,0 | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 10 399,9 | - | - | 550,0 | 600,0 | 600,0 | 600,0 | 64 000,0 |
| | нәзек һәм ярымнәзек йон җитештерү һәм реализациялəүне үстерүгә субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | терлекчелекне үстерүгә субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | - | - | * | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 99 800,0 | 544 544,8 | 2 730 217,0 | 63 000,0 | 81 339,0 | 81 339,0 | 81 339,0 | - |
| | «Терлекчелек объектларын төзүгә дәүләт ярдәме күрсәтү» төп чарасы, шул исәптән: | федераль бюджет* | - | - | 3 582,6 | 1 092 987,8 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 189,0 | 57 525,7 | - | 30 000,0 | 30 000,0 | - |
| | сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары объектларын (сөт фермаларын) төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр | федераль бюджет* | - | - | 3 582,6 | 1 092 987,8 | - | * | * | * |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 189,0 | 57 525,7 | - | 30 000,0 | 30 000,0 | - |
| | «Хайваннар авыруларын кисәтү һәм халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан саклау» төп чарасы, шул исәптән: | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | 71 245,6 | 71 245,6 | 71 245,6 |
| | түләмәле үләт базларын һәм билтермик чокырларны карап тоту чаралары | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хуҗалары булмаган хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу чаралары | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | 46 582,5 | 46 582,5 | 46 582,5 |

* Федераль бюджет акчасы күләмнәре Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары ел саен төзи торган килешүләр нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу шартларында җәлеп итәргә планлаштырыла һәм Татарстан Республикасы бюджетына биреләчәк.».

2. 2018 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 ноябрь, 842 нче; 2017 ел, 15 август, 577 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасының I бүлегендәге җитмеш бишенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенең 28 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 24 сентябрь, 672 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 24 сентябрь, 672 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 апрель, 273 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының инвестицион меморандумын раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1048 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 июнь, 452 нче; 2017 ел, 5 октябрь, 762 нче карары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2017 елга Татарстан Республикасы инвестицион меморандумының 7 бүлегендәге егерме җиденче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин